РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.03.2019 Олы Кайбыч авылы № 21

**2016нчы елның 1нче декабрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы карары белән расланган 92нче номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

2017нче елның 27нче ноябрендәге 355-ФЗ номерлы ««Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртипләре турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы, 2018нче елның 27нче декабрендәге 528-ФЗ номерлы « Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә алга китеп социаль-икътисадый үсеш кичерүче территорияләр турында» Федераль законының 22ст. 2 өлеш 2ст.сының гамәлдән чыгуы турында» Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы

**КАРАР КЫЛАМ:**

1. 2016нчы елның 1нче декабрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы карары белән расланган 92нче номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы аппараты вазыйфаи затларының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2 пунктның 3 абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка электрон документ формасында килгән мөрәҗәгать 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законында

билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә гражданин мәҗбүри рәвештә фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (соңгысын - булган очракта), җавап, башка адреска җибәрү турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтә. Гражданин мондый мөрәҗәгатькә электрон формада кирәкле документлар һәм материалларны теркәүгә хокуклы»;

1.12 пунктны түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«1.12. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауга җавап бирү дәүләт сере яки федераль закон белән саклана торган башка серне ачу белән бәйле булса, мөрәҗәгать җибәрүче гражданинга, әйтелгән мәгълүматларны тарату мөмкин булмау сәбәпле тиешле җавап биреп булмавы турында хәбәр ителә»;

1.13 пункт түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«1.13. әгәр язмача мөрәҗәгать, гариза яки шикаять тексты мәсьәләнең асылын аңларлык булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул компетенцияләре нигезендә Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка карарга җибәрелми, бу хакта мөрәҗәгать теркәлгән көннән башлап җиде көн эчендә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә»;

2.15 пунктының 3нче абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка электрон формада җибәрелгән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ формасында җибәрелә, һәм җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка язма формада килгән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма формада җибәрелә. Моннан тыш, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатьтә аерым затлар мәнфәгатьләренә карый торган тәкъдим, гариза яки шикаять, аерым алганда мөрәҗәгать аерым затларга карата чыгарылган суд карарын яңадан карауны сораса, җавап, шул исәптән суд карарын кире яңадан тәртибен аңлатып, 2006нчы елның 2нче маендагы 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законның 2өлеше 6ст. нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

2.15 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 4 абзац белән тулыландырырга:

«Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка язма формада килгән мөрәҗәгатькә җавап Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенең 2.15пунктының 3 абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырылса, мөрәҗәгать җибәргән гражданинга мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң 7 көн эчендә мөрәҗәгатькә җавап урнаштырылган Интернет челтәрендәге рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, шуның белән бергә, суд карарын яңадан карауны сорый торган мөрәҗәгать кире кайтарылмый.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан

“Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**А.И. Рәхмәтуллин**